СОВЕТ БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

30.11.2023 Баулы шәһәре № 228

Баулы муниципаль район Советының
2018 елның 3 июлендәге 159 номерлы
“Татарстан Республикасы “Баулы муниципаль
районы” муниципаль берәмлегендә
муниципаль хезмәт турында”
карарына үзгәрешләр кертү турында

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 2 ноябрендәге 99-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законына ярашлы Баулы муниципаль район Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Баулы муниципаль районы Советының 2018 елның 3 июлендәге 159 номерлы «Татарстан Республикасы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында» карарына (Баулы муниципаль район Советының 2019 елның 25 февралендәге 196 номерлы, 2020 елның 29 маендагы 264 номерлы, 2020 елның 23 октябрендәге 16 номерлы, 2021 елның 18 февралендәге 36 номерлы, 2022 елның 18 августындагы 122 номерлы, 02.02.2023 елның 2 февралендәге 161 номерлы, 2023 елның 14 апрелендәге 174 номерлы, от 2023 елның 14 августындагы 211 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

10 статьяда:

11 пунктта икенче җөмләне төшереп калдырырга;

17 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

20 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20. Муниципаль хезмәткәрләргә класс чины бирү турында карар, әлеге статьяның 13 өлешендә күрсәтелгән очраклардан тыш, барлык кирәкле документлар белән класс чины бирү турында тәкъдим кертелгән көннән алып, бер айдан да соңга калмыйча, класс чинын

бирү вәкаләтлесе булган органга яки җирле үзидарә вазифаи затына класс чины бирү турында карар кабул ителергә тиеш.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми бастырылып (халыкка җиткерелгән) көннән алып үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль район Советының җирле үзидарә, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы
Район Советы рәисе И.И. Гозәеров